**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында Балтач авыл җирлегендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**

**2022 елның 11 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авылында гражданнар җыены карар итте:

1.2023 елда, 1 төркем инвалидлардан тыш, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Балтач авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау (сатып алу, төяү, ташу, грунт һәм вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Балтач авылы, Школьная ур., 1 йорт, СДК бинасы;
- ТР Кама Тамагы районы Балтач авылы Школьная ур., 2 йорт, кибет бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге башлыгы: Д.И. Мөхәммәдуллин